

Бүгенге кондә олкән яшьтәге ветераннарны ойләренә барып тәбрик итү күркәм гадәткә әверелде. Юбилярлар белән очрашу вакытында төрле язмышлар, гыйбрәтле хәлләр, мона кадәр беркайда да ишетелмәгән зур батырлык-лар ачыла.
Әле генә Кадошкино районы Большая Поляна авылында гомер итүче Халилә Хаким кызы Нарбекова 90-яшьлек Юбилеен билгеләп үтте. Бу конне Россия президенты В.В.Путиннын котлавын да алды. Гади хезмәт иясенә хөкүмәт исеменнән гади, әмма берничә юлга сыйган күнелне жилкендергеч кыйммәтле сүзләрне кабул итү - тарихи момент. Халилә Хаким кызынын тормыш юлы яшьтәшләренекеннән аерылгысыз. Кочле рухлылар буынныннан. Бу гасыр кешеләре жилкәләренә авыр еллар туры килә. Язмышы анын Боек Ватан сугышы, аннан сонгы тергезү елларына үз эченә ала: гаилә мәшәкатьләре, балалар, колхоз эшләре, оныклар - тугыз дистәгә сыйдырган тормыш. Үзләре турында уйларга вакыт та булмаган буын кешеләре бар кочләрен бер «кирәк!» дигәнгә буйсынганнар: фронтка – кирәк, колхозны күтәрергә – кирәк, авылга, районга, Ватанга – кирәк! Язма героебызнын алдына куйган девизы да: «Мин булмасам, кем?» дип яши. Гади кешенен гади хезмәтен олы бәяләп, Ил житәкчесе үзе Халилә Хаким кызы Нарбековага «Рәхмәт!» әйтә.
- Шундый зур Рәхмәт сүзләрен кабул итеп алырмын дип уйламаган идем, - ди Халилә Хакимовна. – Безнен буын кешеләре рәхмәт очен эшләмәдек тә. Балачакчан үк хезмәтебез авылыбызга, районыбызга, Мордовиягә, Россиягә кирәк дип анлап тордык. Үндүрт яшьтән туган авылым сыерлар фермасына сот савучы булып эшкә урнаштым. Фермада нинди авыр хезмәт! Әйе, һәрбер эштә коч, намус һәм тырышлык кирәк. Уйлап карагыз, утыз биш ел чамасы сыер саудым. Тормыш иптәшем Закарья Шакир улы да терлекче (животновод) иде. Икәү Рафик, Наилә һәм Роза балаларыбызны тәрбияләп үстердек. Жәмгыять эшләре белән дә шогыльләнергә вакыт таба идек. Жиде ел дәвамында район Советы депутатлары итеп сайландык. Исам очен тырыштык. Безнен дәвер кешеләре үз куллары белән яна тормыш тозеде. Авылыбыз үсте һәм нык иде, ирешкән нәтиҗәләре белән «Победа» колхозыбыз тирә-якта дан тотты. Мина дип аталган Россия Президенты Рәхмәт сүзләре минем белән шул гасырда хезмәт иткән

барча яшьтәшләремә дә багышлана дип уйлыйм. Кызганычка каршы, авылыбызда алар коннән-кон азаеп килә. Безне искә алган, хормәт иткән очен зур рәхмәтемне белдерәм. Халимә апа Боек Ватан сугышы башланганда яшьvсмер кыз була. Авыр дип тормый, сыер саварга (ул вакыт әле кулда сыерларны сауганнар, сонга гына саву аппаратлары барлыкка килгән) фермага эшкә урнаша, дидек. Биш балалы зур гаиләне туендырырга кирәк бит. Сугыш белән бәхәсләшеп буламыни?! Бер ел vтеп олгерми, анын белән унбиш Иса кызчыгын урман кисәргә – лесозаготовкага озаталар. Ерakka, хәтта Пермь олкәсенә. Андагы kvргәннәрен сойләр очен аерым хикәя багышларга кирәктер дип уйлыйм. Бер ел урман кискәч, кызчыкларны ойләренә жибәрәләр, ә кайтырга транспорт юк. Шулай алар Пермь олкәсеннән Большие Поляныга жәяvләп юлга чыгалар. Ойгә бит кайталар!!! Аяклары vзләре алып бара туган якларга. Шуннан сон Халимә апа туган ягыннан беркайчан беркая чыгып китмәскә дип vзенә cvз бирә. Туган яктан туйган юк, диләр. Бу чынлап та шулай. Туган авылы, мәрхәмәтле, тырыш халкы һәрвакыт ярдәмгә әзерләр, ишекләре килгән кешенен барысына да ачык. Чит жирләрдә сине кем котә... Халилә Хаким кызы Нарбекова, олы яшенә карамастан, оптимист ул; бvген дә алга омтылып яши. Ул тормышта шатланып яшәргә кирәк, авыр булган чакларда да алда якты коннәр килvенә ышанып торырга кирәк, ди. Тошенкелеккә бирелергә сәбәп тә юк, чонки анын биш оныгы һәм дvрт оныкчыгы. Буынын лаеклы дәвам итvчеләре бар. Шуны да әйтеп китәргә кирәк, Халилә апа бәхетле картлык кичерә - Роза кызы гаиләсендә яши. Янында булмаган оныклары, оныкчыклары кунакка еш килеп торалар. Мул тормышларына карап сокланасын. Бәйрәм унаеннан Халилә апага сәламәтлек, коннәренен якты һәм тыныч булуын телибез.

Н.Насырова